ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВВЕДЕНСКО-СЛОБОДСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная, д.55, с. Введенская Слобода,
422591

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ВВЕДЕНСКИЙ БИСТӘСЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Үзәк ур., 55 нче йорт, Введенский бистәсе авылы,
422591

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

12.11.2019 — № 146

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-

с. Введенская Слобода

Гражданнарның үзара салымын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлегенең
Елизаветино авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлеге Уставының 24 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2019 елның 27 ноябрենә Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлеге Елизаветино авылында гражданнарның үзара салым җыю мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Югары Ослан муниципаль районының Елизаветино авылы җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2020 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә ризалыгыгыз бармы?:

- Елизаветино авылында җирле әһәмияттәге юлларны ремонтлау

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Халык җыенын Елизаветино авылы, Солнечная урамы, 19 нчы йорт адресы буенча урнашкан йорт яны территориясендә үткәрергә.

4. Введенский Бистәсе авыл җирлеге Башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Введенский Бистәсе авыл җирлеге
Башлыгы Д.В. Морозов